**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**СОВЕТЫ**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 57** **2019 елның 12 сентябре**

«Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 нче статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. ОД-1 «күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона» территориаль зонасын файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләренә «балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары» һәм « - башлангыч һәм урта мәктәпләр» сүзләрен өстәргә (1 нче кушымта);

1.2. шәһәр төзелешен зоналаштыру һәм территорияләрне файдалануның махсус шартлары булган зоналар карталарында Түбән Уратма авылында санитар-саклау зонасын һәм аларның СН-1 чыганагын төшерергә (2 нче кушымта);

1.3. территорияләрне файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасында автоюлларның санитар аермаларын төшерергә (2 нче кушымта);

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Уратма авыл җирлегенең рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (РФ ТП ФДМС) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р. Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 12 сентябрендәге
5 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ОД-1. Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона**

ОД-1 күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасы күпфункцияле кулланыштагы административ, эшлекле, иҗтимагый, мәдәни, хезмәт күрсәтүче һәм коммерция файдалану төрләре булган киң спектрлы объектларны формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.


**Күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:**

- административ-хуҗалык, эшлекле, иҗтимагый учреждениеләр һәм оешмалар;
- күпфункцияле эшлекле һәм хезмәт күрсәтүче биналар;
- кунаханәләр;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр;
- мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре;
- конфессиональ объектлар;
- дини юнәлештәге уку йортлары;
- клублар;
- ачык, ябык ваклап сату базарлары;
- кибетләр;
- җәмәгать туклануы предприятиеләре;
- көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары;
- прокат пунктлары;
- җәмәгать бәдрәфләре;
- физкультура-спорт комплексы;
- велотреклар;
- спорт мәктәпләре;
- спорт заллары, рекреация заллары (бассейнлы яки бассейнсыз), бассейннар;
- күпмаксатлы һәм махсуслаштырылган билгеләнештәге клублар;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- майданнар;
- урта махсус уку йортлары;
- укыту-җитештерү остаханәләре;
- тулай торак;
- элемтә предприятиеләре;
- полиция участок пунктлары, бүлекчәләр;
- янгын депосы;
- маллар тотмый торган ветеринария шифаханәләре.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 12 сентябрендәге
[illegible] номерлы карарына
[illegible]нче кушымта

**Карта зон с особыми условиями использования территории муниципального образования "Нижнеуратьминское сельское поселение" Нижнекамского муниципального района**




Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина